**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

IV чакырылышның XVII утырышы
**КАРАРЫ**

« 13 » февраль 2024 ел № 2 Урыссу ш.т.б.

2023 елга Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районының
социаль-икътисадый үсеше йомгаклары
һәм 2024 елга бурычлар хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2020 елның 28 апрелендәге 18 санлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башлыгы А.Ә. Шәфигуллинның «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының 2023 елга социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2024 елга бурычлар турында»гы докладын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башлыгы А.Ә. Шәфигуллинның «2023 елга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2024 елга бурычлар турында»гы хисабын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетына 2024 елның 15 мартына кадәр вакытка:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башлыгы хисабында, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары - Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы депутатлары чыгышларында әйтелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру буенча чаралар планын эшләргә һәм аны Татарстан Республикасы Ютазы район Советына карауга тәкъдим итәргә;

- Максаты икътисадны тотрыклы, динамикалы үстерү һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районында яшәүчеләр өчен уңайлы мохит булдыру нигезендә халыкның тормыш сыйфатын яхшыртырга тиеш булган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районын социаль-икътисадый үстерү планнарын уңышлы үтәүне тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетына, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы составына керүче авыл һәм шәһәр җирлекләре башлыкларына тәкъдим итәргә:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы составына керүче авыл һәм шәһәр җирлекләрен һәм тулаем Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районын комплекслы социаль-икътисадый үстерүгә аерым игътибар бирергә;

- салым салу базасын булдыру, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы составына керүче авыл һәм шәһәр җирлеге бюджетларына җирле әһәмияттәге сорауларны хәл итү буенча өстәмә финанс чараларын җәлеп итү буенча эшчәнлекне активлаштырырга;

- халыкның тормыш дәрәҗәсен төшерүгә юл куймау һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы һәм Ютазы муниципаль районы составына керүче авыл һәм шәһәр җирлекләрендә гражданнарның социаль хезмәт күрсәтүләрне тигез алу мөмкинлеген тәэмин итү чараларын күрергә;

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы составына керүче авыл һәм шәһәр җирлекләрен һәм тулаем Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районын төзекләндерү, яшелләндерү һәм торак пунктларны санитар чистарту, экологик иминлек тәэмин итү буенча чараларны дәвам итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карар кабул ителгәннән соң үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Ютазы район Советының даими комиссияләренә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы башлыгы,
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин